СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.12.2017 с. Набережные Моркваши 45-193

Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 01.08.2011 № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә Җир кадастр бәясеннән 0,2 % күләмендә җир салымының түбәнәйтелгән ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча салым ташламасын күздә тотарга:
– ирекле янгын сагы җәмәгать берләшмәләренә;
– ирекле янгын сагы хезмәткәрләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 абзацында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир участогы (өлешләре) булган җир кишәрлекләренә карата бирелә, салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы өчен генә бирелә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир салымы ташламалары хокукына ия затлар салым салу объекты дип таныла торган мөлкәтнең урнашу урыны буенча салым органына әлеге ташламаны алу хокукын раслаучы документларны мөстәкыйль тапшыралар.
4. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен кертә.

Совет рәисе
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______________И.Х.Гаязов